**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Мичурин, Куйбышев, Заря, Насыйров, Х. Такташ урамнарында теркәлгән гражданнар җыены карары**

**18.11.2025 ел, № 2**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Мичурин ур., Куйбышев ур., Заря ур., Насыйров ур., Х.Такташ урамнарында теркәлгән гражданнар җыены
карар кылды:
2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Мичурин, Куйбышев, Заря, Насыйров, Х. Такташ урамнарында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылганнар кертелми яисә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Карабаш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Мичурин, Куйбышев, Заря, Насыйров, Х. Такташ урамнарында теркәлгән I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары; срочная хезмәттәге хәрби хезмәткәрләр; махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә һәм түбәндәге эшләрне башкарырга : күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар тоту, (капкаларны алмаштыру, янәшәдәге территорияләргә ВКПС салу, Карабаш зираты территориясендәге агачларны карау).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**"Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлек башлыгы ____________ И. И. Җәләев**